СОВЕТ НОВОРУССКО-МАМАТКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ЯҢА РУС МӘМӘТХУҖАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

17.12.2015 с. Старое Русское Маматкозино № 4-27

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., 20 ст. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 1 п. 1 п., Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Уставының 11 ст.нигезендә

Югары ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләр буенча уртак инициативасын чыгарырга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчаларны юллауга риза булырсызмы:

- Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге территориясендә урнашкан халыкны су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Яңа Рус Мәмәтхуҗасы авыл җирлеге башлыгы В. Н. Матвеева